ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 24 декабре
№ 1283-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2021 елның 24 декабрендәге
1283-VI ДС номерлы карары
белән расланды

## 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы

| №<br>т/б | Чара исеме | Үткәрү вакытлары | Җаваплылар |
|---|---|---|---|

### 1. Россия Федерациясе субъектларының, башка дәүләтләрнең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән хезмәттәшлек турында килешүләр төзегән парламентлары белән хезмәттәшлек

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.1. | Хезмәттәшлек турында килешүләрне һәм беркетмәләрне гамәлгә ашыру кысаларында ике яклы парламент төркемнәренең хезмәттәшлеге турында килешүләрне һәм беркетмәләрне гамәлгә ашыру буенча уртак эшче комиссияләр төзү:<br><br>а) закон чыгару эшчәнлеге һәм контроль эшчәнлеге тәҗрибәсен алмашу<br><br>б) закон актларын һәм эчке куллану документларын (парламентлар регламентларын, комитетлар һәм комиссияләр турында, аппаратлар хакында нигезләмәләрне һ.б.), | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | парламент эшчәнлеге турында мәгълүмат-аналитика материалларын, шулай ук Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кергән закон чыгару инициативалары проектларын алмашу | | |
| | в) закон чыгару эшчәнлеге мәсьәләләре буенча уртак конференцияләр, семинарлар, «түгәрәк өстәл»ләр үткәрү | | |
| | г) Россия Федерациясе субъектлары парламентларының утырышларында катнашу (визитлар кысаларында) | | |
| 1.2. | Татарстан Республикасы парламент делегацияләренең Россия Федерациясе субъектларына һәм чит илләргә визитларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру (рәсми чакырулар буенча) | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |

## 2. Парламентара багланышларны үстерү

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.1. | Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары (Карачай-Черкес Республикасы, Түбән Новгород өлкәсе, Сахалин өлкәсе, Санкт-Петербург | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | шәһәре), чит дәүләтләр һәм чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре (Беларусь Республикасының Минск өлкәсе, Төркия Республикасы) парламентлары белән мәгълүмати һәм башка багланышларны киңәйтү, тәҗрибә өйрәнү һәм хезмәттәшлекне үстерү | | |
| 2.2. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында чит дәүләтләр делегацияләрен кабул итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты |
| 2.3. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профессиональ даими нигездә эшләүче депутатларының Татарстан Республикасы Президенты җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы рәсми делегацияләре | ел дәвамында (аерым график буенча) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, Татарстан |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | визитларында катнашуы | | Республикасы Президенты Аппараты |
| 2.4. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының халыкара форумнарда һәм конференцияләрдә катнашуы. Килә торган делегацияләр белән эшләү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 2.5. | «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе һәм Идел буе федераль округы хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары хатын-кыз депутатлары катнашында дискуссия мәйданчыклары утырышлары | квартал саен | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе |

**3. Федераль һәм халыкара оешмалар белән хезмәттәшлек**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.1. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Россия Федерациясе Федераль Собраниесе каршындагы Россия Федерациясе Закон чыгаручылар советы эшендә катнашуы. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары җитәкчеләре | Закон чыгаручылар советы эше планы нигезендә ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе (Закон чыгаручылар советы Президиумы әгъзасы һәм Халыкара хезмәттәшлек проблемалары комиссиясе рәисе буларак), Татарстан |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | белән очрашулар. Россия Федерациясе Закон чыгаручылар советының Халыкара хезмәттәшлек проблемалары комиссиясе эшен оештыру | | Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты |
| 3.2. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Идел буе федераль округындагы Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары ассоциациясе эшендә катнашуы. Идел буе федераль округындагы Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары җитәкчеләре белән очрашулар | Ассоциация утырышлары планы нигезендә ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты |
| 3.3. | Европа Советының Җирле һәм региональ хакимиятләр конгрессы эшендә катнашу | ел дәвамында (аерым график буенча) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе (Европа Советының Җирле һәм региональ хакимиятләр конгрессының Мактаулы әгъзасы буларак) |

**4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының һәм комиссияләренең парламентара хезмәттәшлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.1. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының Россия | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советының һәм Дәүләт Думасының профильле комитетлары белән хезмәттәшлеге Парламент тыңлауларында, «түгәрәк өстәл»ләрдә һәм башка чараларда катнашу | | комитетлары |
| 4.2. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының түбәндәге профильле комитетлар (комиссияләр) белән хезмәттәшлеге: | | |
| | а) Россия Федерациясе субъектлары парламентлары | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| | б) Идел буе федераль округы составына керүче Россия Федерациясе субъектлары парламентлары | ел дәвамында | Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты, Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты, Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты, Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты |
| 4.3. | Түбәндәге мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе | ел дәвамында | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | субъектлары тәҗрибәсен өйрәнү: | | |
| | - җирле үзидарә турындагы законнарны гамәлгә ашыру | | Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты |
| | - Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты карамагындагы мәсьәләләр буенча тәҗрибәне өйрәнү | | Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты |
| 4.4. | Башкортостан Республикасы Нефтекамск шәһәрендә «Халыклар рухиятен булдыруда һәм традицияләрен үстерүдә милли мәдәниятләрнең роле» дигән темага Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның Мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт комитеты белән уртак утырыш үткәрү | май | Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты |
| 4.5. | Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте закон чыгару органнары ассоциациясенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендәге реформаның хокукый аспектлары турында» мәсьәләсе карала торган киңәйтелгән утырышын оештыруда катнашу | I квартал | Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты Оештыру идарәсе (Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары белән берлектә) |

## 5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында фракцияләрнең парламентара хезмәттәшлеге

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5.1. | «Закон чыгару (вәкиллекле) органнарында «ЕДИНАЯ РОССИЯ» фракцияләренең муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарында «Единая Россия» депутат берләшмәләре һәм төркемнәре белән үзара хезмәттәшлеге турында» дигән темага видео-конференция элемтәсе режимында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының һәм Самара губерна Думасының «ЕДИНАЯ РОССИЯ» фракцияләренең уртак утырышын үткәрү | II квартал | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «ЕДИНАЯ РОССИЯ» фракциясе җитәкчесе |
| 5.2. | Идел буе федераль округының закон чыгару органнары катнашында торак-коммуналь хуҗалык проблемалары буенча уртак «түгәрәк өстәл»ләр үткәрү | бер елга ике тапкыр | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе җитәкчесе |
| 5.3. | Идел буе федераль округының закон чыгару органнарында КПРФ фракцияләре депутатлары белән торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе җитәкчесе |

## 6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының парламентара хезмәттәшлеге

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6.1. | Санкт-Петербург Закон чыгару Собраниесе, Мәскәү өлкә Думасы, Самара өлкә Думасы аппаратларының эш тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Оештыру идарәсе<br>Эшләр идарәсе<br>Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 6.2. | Саха (Якутия) Республикасы һәм Иркутск өлкәсе закон чыгару (вәкиллекле) органнарының закон чыгару эшенең уңай тәҗрибәсен куллану | ел дәвамында | Хокук идарәсе |
| 6.3. | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы һәм Дәүләт Думасы комитетлары, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару органнары аппаратларының эш тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты, Оештыру идарәсе |
| 6.4. | Кырым Республикасы Дәүләт Советы һәм Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтае аппаратларының Идарә карамагындагы мәсьәләләр буенча эш тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Документлар белән тәэмин итү идарәсе |
| 6.5. | Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтае | ел дәвамында | Матбугат хезмәте |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Матбугат үзәгенең эш тәҗрибәсен, контент булдыруның, андагы карауларны арттыруның һәм аларның колачын киңәйтүнең заманча механизмнарын һәм алымнарын кертү тәҗрибәсен өйрәнү | | |
| 6.6. | Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) органнарының һәм чит дәүләтләрнең закон чыгару органнарының парламент эшчәнлеген тәэмин итүдә мәгълүмати системаларны эксплуатацияләү буенча эш тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Эшләр идарәсе |
| 6.7. | Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның аерым юнәлешләр буенча эшчәнлек тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Яшеренлек режимын тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы секторы |